Хәеретдинова, Л. Тылсымлы агач: [8нче китапханә хезмәткәрләре гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көненә багышланган чара үткәрделәр] / Л. Хәеретдинова // Көмеш кыңгырау. – 2025. – №28 (19 июль). – Б. 2.

# Тылсымлы агач

**Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көнендә 8нче балалар китапханәсендә тылсымлы гаилә агачы «үсеп» чыкты. Бу чарада китап сөюче дусларыбыз бик теләп катнашты.**



Алар алдан әзерләнгән кәгазь яфракларга якыннары турында җылы сүзләр язды, матур хисләре белән уртаклашты. Әйтик, «Минем әни - иң яхшысы», «һәр гаилә бәхетле булсын», «Әти-әнигә рәхмәт» кебек ихлас сүзләр язылганнары да бар иде. Кемнәрдер уртак шөгыльләре турында да сөйләде. Шулай итеп, җылылык һәм мәхәббәткә төренгән «яфраклар»ны дусларыбыз «Гаилә агачы»на беркеттеләр. Тылсымлы агач бердәмлек һәм гаилә символына әверелде.



Шулай ук мәхәббәт һәм дуслык турында мавыктыргыч китаплар күргәзмәсе оештырылды. Балалар һәм әти-әниләр гаилә белән бергәләп уку өчен яңа китаплар сайладылар, һәр катнашучыга гаилә нигезләре турында зирәк искәртмә дә бирелде.

**Ләйсән ХӘЕРТДИНОВА,**
*Яр Чаллы шәһәре.*